ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

КАРАР

17 октябрь, 2024 ел. № 10

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Суровка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 08 ноябрендәге 41/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 29 октябрь көнне 2024 елның сәгать 18.00 Суровка авылында Новая, Мира, Дружбы, Юности, Строительная, Индустриальная, 1 нче Строительный тыкрыгы, 2 нче Строительный тыкрыгы, 3 нче Строительный тыкрыгы, 4 нче Строительный тыкрыгы, Строительный юлы, Вишневая, Кленовая, Северная, Столбовая, Заречная 26-27 санлы урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 29 октябрь көнне 2024 елның сәгать 19.00 Суровка авылында Молодежная, Сиреневая, Раздольная, Посадская, Васильковая, Земляничная, Камская, Бирюсинка, Светлая, Отрадная, Южная, 70 лет Победы, Интернациональная, Лазурная, Спортивная, Тукая, Пушкина, Гагарина, Парковая, Подрядная, Крайняя, Ясная, Ключевая, Хорошая урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 30 октябрь көнне 2024 елның сәгать 18.00 Суровка авылында Чехова урамында, Заречная, Октябрьская, Авангард комплексы, 1 Мая урамынарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Халык җыенын уздыру өчен Суровка авылы яшәүчеләренең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен

киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә әлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Суровка авылында вак таш сатып алу);

- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Суровка авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Суровка авылында янгын сүндерү гидрантлары урнаштыру)

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Суровка авылында мафлар урнаштыру).

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Суровка авылы, Поперечная урамы, балалар мәйданчыгы янында.
7. Халык җыенын икенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Суровка авылы, Молодежная урамы, балалар мәйданчыгы янында.
8. Халык җыенын өченче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Суровка авылы, Чехов урамы, 1а йорт янында үткәрергә («Элис Маркет» кибете янында).
9. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.
10. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.
11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

12. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева